## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
## ЮГАРЫ СӘРДӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

08 ноябрь 2022 ел № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге **Югары Сәрдә** торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 19.11.2022 ел Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 19 ноябрь 2022 ел 14.00 сәгатькә;
- үткәрү урыны – Югары Сәрдә авылы, Узяк урамы, 21 йорт:

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итергә:
- 2022 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Югары Сәрдә авылы, Узяк урамы, 21 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Югары Сәрдә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Югары Сәрдә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итергә;

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Югары Сәрдә авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) Югары Сәрдә авыллы зираты территориясен төзекләндерү һәм чистарту агач һәм куакларны кисү, чистарту; (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Алмяш, Тургай, Яшеллек урамнары буенча Югары Сәрдә авылы урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муницпаль берәмлекләре порталында “Интрернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Югары Сәрдә авыл җирлеге мәгълүмәтләр стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Хөснетдинов